КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 8 ноябрь г.Казань № 920

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының бердәм архив мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне һәм «Татарстан Республикасының бердәм архив мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланучыларның үзара мәгълүмати хезмәттәшлеге регламентын раслау хакында» 2018 ел, 22 сентябрь, 836 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының бердәм архив мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне һәм «Татарстан Республикасының бердәм архив мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланучыларның үзара мәгълүмати хезмәттәшлеге регламентын раслау хакында» 2018 ел, 22 сентябрь, 836 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 6 пункты нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Архив фонды документларында һәм башка архив документларында булган мәгълүматны алуга җәмгыятьнең агымдагы ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм дәүләт идарәсе системасын документлар белән тәэмин итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»

3 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 - 2020 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 ел, 10 июнь, 395 нче карары белән расланган «2016 -

2020 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2016 ел, 10 июнь, 395 карары белән расланган «Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасының Бердәм архив мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктка «Нигезләмә» сүзеннән соң «Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасының Законының 5 статьясындагы 6 пункты нигезендә» сүзләрен өстәргә;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

муниципаль архив – Татарстан Республикасының Архив фонды документларын, шулай ук башка архив документларын саклау, комплектлау, исәпкә алу һәм куллануны гамәлгә ашыра торган җирле үзидарә органы структур бүлекчәсе яки муниципаль берәмлек тарафыннан булдырылган муниципаль учреждение;

«Бердәм архив мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – дәүләт мәгълүмат системасы) – дәүләт һәм муниципаль архивларда саклаучы архив документларының электрон мәгълүмат ресурсларын саклау, актуаль хәлдә тоту һәм куллану өчен билгеләнгән программалы-аппарат комплексы;

оператор – дәүләт мәгълүмат системасын эксплуатацияләү, шул исәптән аның мәгълүмат базаларында булган мәгълүматны эшкәртү буенча эшчәнлек башкаручы республика башкарма хакимият органы;

дәүләт һәм муниципаль архивларны архив документлары белән комплектлау чыганаклары (алга таба – комплектлау чыганаклары) – эшчәнлекләре процессында Россия Федерациясенең Архив фонды документлары һәм дәүләт һәм муниципаль архивларга саклауга кабул ителергә тиешле башка архив документлары барлыкка килгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм гражданнар.»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт мәгълүмат системасы түбәндәге функцияләрне үтәүне тәэмин итә:

а) архив документларының төп нөсхәләрен электрон рәвештә автоматлаштырылган комплектлау, архив документларының төп нөсхәләрен электрон рәвештә саклауга кабул итү-тапшыру, электрон рәвештә саклауга тапшырыла торган архив документларының төп нөсхәләре составын һәм бөтенлеген автоматлаштырылган тикшерү;

б) электрон рәвештәге архив документларының төп нөсхәләрен теркәү;

в) электрон рәвештәге архив документларының төп нөсхәләрен саклау;

г) электрон рәвештә саклау өчен билгеләнгән архив документларын күпләп сканерлау, архив документларын тану һәм атрибутлау юлы белән электрон мәгълүмат ресурсын булдыру. Булдырылган электрон мәгълүмат ресурсы дәүләт мәгълүмат системасына йөкләнергә тиеш, анда алга таба аның саклануы һәм үзара мәгълүмати бәйләнештә катнашучылар тарафыннан кулланылуы тәэмин ителә;

д) муниципаль архивлар тарафыннан аларда саклаучы архив документларын ерактан файдалану хезмәтен күрсәтү.»;

2.1 пунктка «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» сүзләреннән соң «(алга таба – ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты)» сүзләрен өстәргә, «Татарстан Республикасы муниципаль архивлары» сүзләрен «муниципаль архивлар» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктта:

беренче абзацта «Мәгълүмат системасының бурычлары» сүзләрен «Дәүләт мәгълүмат системасының бурычлары» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «Татарстан Республикасы муниципаль архивлары» сүзләрен «муниципаль архивлар» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.2 пунктта «Татарстан Республикасы муниципаль архивлары» сүзләрен «муниципаль архивлар, комплектлау чыганаклары» сүзләренә алмаштырырга;

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Дәүләт мәгълүмат системасында Кулланучыларны теркәү өчен, шулай ук системада булган белешмә-эзләү чараларын куллану өчен түләү алынмый.»;

3.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9. Татарстан Республикасы Архив фондына кергән, архив тарафыннан электрон рәвешкә әйләндерелгән архив документларының электрон күчермәләрен карау һәм (яки) тыңлау өлешендә архив документларын ерак куллану хезмәте күрсәтү өчен архив документларын кулланучылардан түләү алынмый, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән очраклардан тыш.»;

3.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10. Хезмәткәрләрнең аутентификациясе Оператор тарафыннан булдырылган исәп язмалары кулланып башкарыла. Комплектлау чыганаклары һәм уку залына килүчеләр «Электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада идентификация һәм аутентификациянең ярдәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша авторизация ярдәмендә системага керәләр.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.11 пункт өстәргә:

«3.11. Дәүләт мәгълүмат системасына керү керү хокукларына туры китереп чикләнә (Оператор, хезмәткәрләр, уку залларына килүчеләр, комплектлау чыганаклары).»;

түбәндәге эчтәлекле 3.12 пункт өстәргә:

«3.12. Дәүләт мәгълүмат системасы Татарстан Республикасы дәүләт архивының программалы, техник һәм матди ресурсларында урнаштырылган.»;

IV бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Дәүләт мәгълүмат системасының структурасы

4.1. Дәүләт мәгълүмат системасына керә:

«Мәҗбүри экземпляр һәм Аудиовизуаль документларның архив фонды белән автоматлаштырылган идарә итү системасы» программалы комплексы;

«Мәҗбүри экземпляр һәм Аудиовизуаль документларның архив фонды белән автоматлаштырылган идарә итү системасы» программалы тәэминаты;

системаның:

архив документлары буенча тулы текстлы эзләү системасы;

эшләр хәрәкәтен автоматлаштырылган исәпкә алу системасы;

фотосурәтләрне график эшкәртү системасы;

ярдәмче системалар:

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты ярдәмче системасы;

муниципаль архивлар, комплектлау чыганаклары ярдәмче системасы;

хезмәтләр күрсәтү өчен тышкы мәгълүмат системалары белән интеграция ярдәмче системасы;

идарә итү ярдәмче системасы;

«Дәүләт мәгълүмат системасының Россия Федерациясе Социаль фондының мәгълүмат системасы белән үзара эшчәнлеге» веб-сервисы;

«Соратуларны кабул итүне һәм үтәүне исәпкә алу» модуле (соратулар белән идарә итү, соратуларны эшкәртү, соратуларны үтәү);

«Хисап-статистик документлар» модуле;

«Уку залы» модуле (читтән торып уку залы);

«Агымдагы кертү» модуле;

«Архив фонды» программа комплексы белән үзара бәйләнеш модуле;

«Саклау урыннары топографиясен алып бару» (эшкәртү, штрихкодлау) модуле;

«Кулланучының шәхси кабинеты сервислары» модуле;

«Планлы эшләр» модуле;

«Саклау срокларын контрольдә тоту» модуле;

«Архив документларын фондтан тыш оештыру» модуле;

«Түләүле хезмәтләр» модуле;

«Администрирование» модуле;

«Документларны электрон рәвештә даими саклауга кабул итү» модуле;

«Басма продукциянең мәҗбүри нөсхәсен кабул итү» модуле;

«Реставрация эшләре» модуле;

«Эксперт-тикшерү комиссиясе» модуле (алга таба – ЭПК);

комплектлау чыганаклары булган һәм булмаган оешмалар белән үзара бәйләнеш модуле;

«Таләпләр белән идарә итү» модуле;

цифрлаштыру һәм индекслау биремнәрен үтәү өчен модуль;

«Оешмаларның универсаль белешмәлеге» модуле;

«Реставрация эшләрен планлаштыру һәм исәпкә алу» модуле.»;

V бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүматның техник яклавын тәэмин итү

5.1. Система дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүмат белән эшләү өчен билгеләнмәгән.

5.2. Системада мәгълүмат эшкәртү вакытында техник яклау чаралары мәҗбүри булып тора.

5.3. Дәүләт мәгълүмат системасындагы мәгълүматны яклау, Заказчы тарафыннан системадагы мәгълүматны яклауны оештыру таләпләрен үтәү юлы белән тәэмин ителә.

5.4. Системадагы мәгълүматны яклау дәүләт мәгълүмат системасын булдыру һәм эксплуатацияләү эшләренең состав өлеше булып тора һәм, мәгълүматны яклау системасы (ярдәмче системалар) кысаларында, дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат куркынычсызлыгы янауларын блоклау (нейтральләштерү) юнәлешендә мәгълүматны яклауның оештыру һәм техник чараларын кабул итү юлы белән тәэмин ителә.

5.5. Системада яклау объектлары булып дәүләт мәгълүмат системасындагы мәгълүмат, техник чаралар, гомуми системалы, кулланма, махсус программа тәэминаты, шулай ук мәгълүматны яклау чаралары тора.

5.6. Платформаның техник (аппарат) һәм программа чаралары тәэмин итә:

а) платформаның эчтәлегендәге мәгълүматны саклау, шул исәптән аны күчерүдән, тарату, юк итү, үзгәртү һәм аңа керүне томалау, шулай ук башка хокуксыз гамәлләрдән саклау;

б) электрон рәвештәге архив документларының төп нөсхәләрен саклауга җибәргәндә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куллану, шулай ук мәгълүмат саклау дәвамында электрон имзаның чынлыгын тикшерү мөмкинлеге;

в) платформаны кулланучыларның керү хокукларын чикләү;

г) электрон рәвештәге архив документларының төп нөсхәләрен җибәрү, саклау һәм бетерү буенча барлык гамәлләрне исәпкә алу мөмкинлеге белән, платформада операция ясаган кулланучылар турында төгәл вакытны, күрсәтелгән гамәлләрне һәм белешмәләрне теркәү мөмкинлеге белән техник (аппарат) һәм программа чаралар кулланып башкарылган операцияләрне исәпкә алу электрон журналларын алып бару,

д) электрон рәвештәге архив документларының төп нөсхәләрен бүленгән резервлы саклау;

е) электрон рәвештәге архив документларының төп нөсхәләрен реквизитлары буенча эзләү.»

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин